КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 май г.Казань № 555

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче; 2016 ел, 18 июнь, 413 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 705 нче; 2019 ел, 8 февраль, 82 нче; 2020 ел, 10 февраль, 84 нче; 2021 ел, 8 июнь, 441 нче; 2022 ел, 19 февраль, 138 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1324 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.5 пунктта:

3.5.3 пунктчаның икенче – дүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

3.5.5 пунктчаның икенче – дүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче;

2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» – «ж» пунктчаларын өстәргә:

«г) хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;

д) «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

е) «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

ж) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм гамәлдәге фронт тылы, гамәлдәге флотларның операция зоналары эчендә булган башка хәрби объектлар төзелешендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзаларына.»;

3.2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» – «ж» пунктчаларын өстәргә:

«г) хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;

д) «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

е) «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

ж) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм гамәлдәге фронт тылы, гамәлдәге флотларның операция зоналары эчендә булган башка хәрби объектлар төзелешендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзаларына.»;

5.1.1 пунктта:

«[*****]» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«[*****]– бу Тәртипнең 5.2.3 пунктындагы «а» – «е» һәм «з» – «к» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияләрдәге социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә бирелми;»;

«[******]» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«[******] – социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә бу Тәртипнең 5.2.3 пунктындагы «а» – «е» һәм «з» – «к» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияләрдәге социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә карамаган граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.»;

5.2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле «и», «к» пунктчаларын өстәргә:

«и) «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

к) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм гамәлдәге фронт тылы, гамәлдәге флотларның

операция зоналары эчендә булган башка хәрби объектлар төзелешендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзаларына.»;

7.2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «в» – «е» пунктчаларын өстәргә:

«в) хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;

г) «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

д) «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

е) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм гамәлдәге фронт тылы, гамәлдәге флотларның операция зоналары эчендә булган башка хәрби объектлар төзелешендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзаларына.»;

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1.1 пунктта:

«***» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*** бу Тәртипнең 2.2.2 пунктындагы «а» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияләрдәге гражданнар тарафыннан бирелми.»;

«****» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**** бу Тәртипнең 2.2.2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән ташламалы категориядәге гражданнар тарафыннан бирелә.»;

«******» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«****** социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә бу Тәртипнең 2.2.2 пунктындагы «а» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның ташламалы категорияләренә кертелмәгән граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.»;

2.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.2. Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексլы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекләрендә түбәндәгеләргә ярымстационар формасындагы социаль хезмәтләр түләүсез күрсәтелә:

а) «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясындагы 1, 2 өлешләрендә күрсәтелгән социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә;

б) социаль адаптациядә авырлыклар кичерүче (шул исәптән опекадагы, попечительлектәге) баласы яки балалары булуга бәйле рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга;

в) гаиләләрендә балигъ булмаган балалар тәрбияләнә торган һәм аларда үзара гаилә низаглары (шул исәптән наркотикка яки исерткеч эчемлеккә бәйлелеге булган затлар, комарлы уеннар белән мавыккан затлар, психик бозылышлар белән интегүче затлар белән), көчләү булуга бәйле рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга;

г) гаиләсендә даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ инвалид бала булуга бәйле рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга;

д) эше булмауга һәм яшәү өчен акчасы булмауга бәйле рәвештә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнарга.»;

3.1.1 пунктта:

«[****]» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«[****] бу Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы «а» – «д» һәм «ж» – «и» пунктчаларында күрсәтелгән ташламалы категорияләрдәге гражданнар тарафыннан бирелми;»;

«[*****]» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«[*****]социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә бу Тәртипнең 3.2.4 пунктындагы «а» – «д» һәм «ж» – «и» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның ташламалы категорияләренә кертелмәгән граждан тарафыннан мөстәкыйль рәвештә декларацияләнә.»;

3.2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле «з», «и» пунктчаларын өстәргә:

«з) «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

и) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм гамәлдәге фронт тылы, гамәлдәге флотларның операция зоналары эчендә булган башка хәрби объектлар төзелешендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган транспорт флоты судънолары экипажлары әгъзаларына.»;

6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.1. Көндезге бүлекләрдә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләр түләүсез яки түләүле яисә өлешчә түләүле (гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турындагы федераль законнар нигезендә һәм бу Тәртипнең I бүлегендәге 1.5 бүлекчәсе нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә) күрсәтелә.

Көндезге бүлекләрдә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр түбәндәгеләргә түләүсез күрсәтелә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидларына;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучыларга;

в) хәрби хәрәкәтләр инвалидларына;

г) «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

д) «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга;

е) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм гамәлдәге фронт тылы, гамәлдәге флотларның операция зоналары эчендә булган башка хәрби объектлар төзелешендә, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларга, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тоткарланган транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзаларына.»;

4. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин